ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮГАРЫ СӘРДӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН ВЕРХНЕСЕРДИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ

422015 Республика Татарстан Атнинский район с. Верхняя Серда. Тел. 3-28-70

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№1 “ 09 ” апрель 2026 ел

**«Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының “Югары Сәрдә авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә муниципаль-хосусый партнерлык турында нигезләмәне раслау хакында» гы 2016 елның 15 декабрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

2025 елның 31 июлендәге 350-ФЗ номерлы «Экс әһәмиятле оешмалар булган хуҗалык җәмгыятьләрендә корпоратив мөнәсәбәтләрне җайга салу үзенчәлекләре турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында " гы Федераль закон нигезендә, 2025 елның 28 декабрендәге 514-ФЗ номерлы "Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»Федераль законның 13 статьясы нормалары белән, шулай ук Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2026 елның 27 мартындагы 02-08-02-2026/Прдп175-26 номерлы протестын карап, карар бирәм:

1. Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгының 2016 елның 15 декабрендәге 4 номерлы карары

( 11.06.2021, № 2, 19.05.2022, № 2, 17.03.2025 №1 номерлы карарлар редакциясендә) белән расланган «Югары Сәрдә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль-хосусый партнерлык турында нигезләмәгә” түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

**1.1. 8 бүлекнең 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7.1. һәм 7.2 пунктчалары өстәргә:**

“7.1. Гавами партнерның һәм хосусый партнерның ризалыгы булганда килешүгә үзгәрешләр кертелергә мөмкин. Бу очракта проектны гамәлгә ашыру турындагы карар нигезендә һәм (яисә) конкурс критерийларына карата хосусый партнерның конкурс тәкъдиме нигезендә билгеләнгән килешү шартларын үзгәртү турындагы карар хосусый партнерның ризалыгы булганда проектны гамәлгә ашыру турында карар кабул иткән муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан кабул ителә.

7.2. Килешүне төзегәннән соң элек килешүне әзерләгәндә һәм (яисә) төзегәндә кулланылган документлар (шул исәптән проектны гамәлгә ашыру турында тәкъдим, проектны гамәлгә ашыру турында карар, конкурс документациясе, конкурста җиңүче тарафыннан тапшырылган конкурс тәкъдиме, конкурс үткәрү нәтиҗәләре турында беркетмә, конкурста җиңүче белән сөйләшүләр беркетмәсе һәм күрсәтелгән документларга кушымта) проектны гамәлгә ашырганда бары тик килешүдә каралган очракларда гына актуальләштерелә һәм файдаланыла, һәм килешүне берьяклы тәртиптә үзгәртү өчен нигез була алмый.».

2. 7.1 пунктчасы 2025 елның 28 декабренә кадәр төзелгән муниципаль-хосусый партнерлык турындагы килешүләргә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы: Хөснетдинов Р.Р.